ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур., 37в нчы йорт. Тел.3-44-63

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная,дом 37в,
Тел. 3-44-63

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«18» ноябрь 2020 ел** **№ 11**

**Усы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 18.11.2020елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Усы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Усы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан кала, 2021 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

* **ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**
зиратларны чистарту, зиратлар территорияләрендә агачлар кисү, зиратларга керү юлларын ремонтлау;
* **җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
«Эреш» чишмәсе өстендә будка монтажлау; Качкын, Усы авылларында балалар мәйданчыгын монтажлау;
* **автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
Усы, Качкын авылларында тыкрыкларын ремонтлау (ком салу, грейдерлау);
* **җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**
Усы авылында Үзәк урам буенча янгын гидранты урнаштырылган өстәмә колонканы монтажлау; суны лицензияләштерү, оешмага тапшыру;
***җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне оештыру:**
урам яктырткычларын ремонтлау һәм алыштыру.

2. Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Усы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Усы авыл җирлеге башлыгы З.З.Ахмаев